ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

__________________________ **г.Чистополь** **№** _______________

Төзелгән яки реконструкцияләнгән
шәхси торак төзелеше яки бакча өе
объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге
законы таләпләренә тәңгәл
килүе (тәңгәл килмәве) турында
белдерү җибәрү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын
раслау турында

Россия Федерациясенең 2003елның 06 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 131 нче номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 210 нчы номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге "Татарстан Республикасы дәүләт властеның башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында"гы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында"гы 880 нче номерлы Карарына таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Кушымта нигезендә төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге законы таләпләренә тәңгәл килүе (тәңгәл килмәве) турында белдерү җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә әлеге карарны Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет
житәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
башкарма комитеты карарына
кушымта

__________ 2019 ел № _______

**Төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге законы таләпләренә тәңгәл килүе (тәңгәл килмәве) турында белдерү җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеге бирүче әлеге административ регламент (алга таба – Регламент) төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге законы таләпләренә тәңгәл килүе (тәңгәл килмәве) турында белдерү җибәрү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

1.2. Хезмәт алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба- гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Чистай муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба – Башкарма комитет).

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Чистай муниципаль районының "Шәһәр төзелешен көйләү һәм инфраструктура үсеше" муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба - Бүлек ).

1.3.1. Башкарма комитет урнашкан урын: : ТР, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт.

Бүлек урнашкан урын: ТР, Чистай шәһәре, К. Маркс урамы, 27 нче йорт.

Эш графигы: дүшәмбе, сишәмбе - 13.00тән 17.00 сәгатькә кадәр

Чәршәмбе, пәнҗешәмбе - 8.00дән 12.00 сәгатькә кадәр.

Җомга – кабул итүләр булмый

Шимбә, якшәмбе – ял көннәре

Ял итү һәм туклану вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре буенча билгеләнә.

Белешмәләр өчен телефон: 8 (84342) 5-14-15, 5-15-54.

Алдан язылу кирәкми.

Керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. Муниципаль районның "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдәге рәсми сайты адресы (алга таба –"Интернет" челтәре): (http://chistopol.tatarstan.ru)

1.3.3. Муниципаль хезмәт, шулай ук Бүлекнең урнашу урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүматны алу мөмкинлекләре:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет (Бүлек) биналарында урнашкан муниципаль хезмәтләр турындагы визуаль һәм текст мәгълүматларыннан торган мәгълүмати стендлар чаралары буенча.

Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат үз эченә әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 нче пунктларында (пунктчаларында) булган муниципаль хезмәт турындагы белешмәне ала;

2) муниципаль районның рәсми сайтындагы «Интернет» челтәре чаралары буенча (http://chistopol.tatarstan.ru);

3) Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatar.ru/);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) Бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта (Бүлектә):

телдән мөрәҗәгать иткәндә –шәхсән яки телефон буенча;

язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ алымы белән) – почта аша кәгазьдә, электрон формада электрон почта аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Учреждение биналарының мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы 29.12.2004 елгы, №190-ФЗы(алга таба – РФ ШтК) (РФ Законнар җыентыгы, 03.01.2005, №1 (1нче өлеш), 16 нчы маддә);

Россия Федерациясенең Җир кодексы 25.10.2001елгы, №136-ФЗы (алга таба – РФ ҖК) (РФ Законнар җыентыгы, 29.10.2001, №44, 4147нче маддә);

17.11.1995 елгы “Россия Федерациясендә архитектура эшчәнлеге турында”гы 169 нчы номерлы Федераль закон ( алга таба -169нчы номерлы Федераль закон) (РФның законнар җыентыгы, 20.11.1995, № 47, 4473нче маддә).

06.10.2003 елда кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131нче номерлы Федераль закон ( алга таба -131нче номерлы Федераль закон) (РФның законнар җыентыгы, 06.10.2003, №40, 3822 нче маддә).

27.07.2010 елда кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210нчы номерлы Федераль закон ( алга таба - 210нчы номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 нчы маддә);

Россия Федерациясенең Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 19.09.2018 елда кабул ителгән “Шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү яки реконструкцияләү өчен кирәк булган белдерүләр формасын раслау турында”гы 591/пр боерыгы (алга таба - 591/пр нче боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 28.09.2018);

Татарстан Республикасының 28.07.2004 елгы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45нче номерлы законы (алга таба – 45 нче номерлы ТР законы) ( Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004);

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2014 елның 29 гыйнварендагы 32/1 нче карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

Чистай муниципаль районы Советы Карары белән расланган Чистай муниципаль районы башкарма комитеты турындагы 16.05.2012 елгы17/4нче Нигезләмә белән (алга таба – БК турындагы нигезләмә);

Башкарма комитет җитәкчесенең 21.03.2006 елгы 106-р нчы номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән (алга таба – Кагыйдә);

Башкарма комитет җитәкчесенең 12.02.2013 елгы 73нче карары белән расланган Чистай муниципаль районының “Шәһәр төзелешен көйләү һәм инфраструктура үсеше” муниципаль бюджет учреждениесе уставы белән (алга таба – Учреждение турында устав).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

гариза бирүче –дәүләт хезмәте күрсәтүче органга яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, 27.07. 2010 елда кабул ителгән 210 нчы номерлы Федераль законының 1 нче маддәсенең 2 һәм 3нче өлешләрендә күрсәтелгән оешмаларга яки әлеге маддәнең 5нче пунктында күрсәтелгән оешмага дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы, шул исәптән әлеге Федераль законның 15.1 нче маддәсе белән билгеләнгән тәртиптә телдән, язмача яки электрон формада белдерелгән сорау белән мөрәҗәгать иткән физик яки юридик зат (дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлар һәм аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнарыннан кала) яисә аларның вәкаләтле вәкилләре;

төзүче – физик яки юридик зат үзенең җир участогында яки башка хокук иясенең (аңа дәүләт (муниципаль) милектәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен тормышка ашырганда дәүләт власте органы (дәүләт органнары), атом энергиясе буенча “Росатом” дәүләт корпорациясе, “Роскосмос” космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, бюджеттан тыш дәүләт фондлары идарәсе органнары яки җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең бюджет законында билгеләнгән очракларда килешү нигезендә үзләренең дәүләт (муниципаль) заказчы вәкаләтләрен тапшыралар) җир участогында капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм сүтү, шулай ук инженерлык эзләнүләре, аларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен проект документациясе әзерләүне тәэмин итүче. Төзүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге буенча үз функцияләрен техник заказчыга тапшырырга хокуклы;

техник заказчы – юридик зат, ул төзүче вәкаләте буенча һәм төзүче исеменнән инженерлык эзләнүләре турында, проект документациясе әзерләү турында, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм сүтү турында килешүләр төзи, күрсәтелгән эш төрләрен үтәүгә биремнәр әзерли, инженерлык эзләнүләре үтәүчеләргә, проект документациясе әзерләүне һәм капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм сүтүне гамәлгә ашыручыларга эшләрнең күрсәтелгән төрләрен үтәү өчен кирәк булган материалларны һәм документларны бирә, проект документациясен раслый, капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт алу өчен кирәк булган документларга имза куя, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон тарафыннан каралган башка функцияләрне башкара (алга таба -

техник заказчы функцияләре). Техник заказчы функцияләре инженерлык эзләнүләре, архитектур-төзелеш проектлавы, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм сүтү өлкәсендәге шул рәвешле үзеннән-үзе көйләнә торган оешмалар әгъзасы тарафыннан гына башкарылырга мөмкин, Шәһәр төзелеше кодексының 47 нче маддәсенең 2.1 өлеше белән, 48 нче маддәсенең 4.1 өлеше белән, 52 нче маддәсенең 2.1 һәм 2.2нче өлеше белән, 55.31 нче маддәсенең 5нче һәм 6 нчы өлешләре белән каралган очраклардан кала;

Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

күпфункцияле үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче читтәге эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 22.12. 2010 елгы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында”гы 1376 нчы карары белән расланган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәсенең 34 нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының ( шәһәр округы) шәһәр яки авыл җирлегендә оештырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур подразделениесе (офис);

техник хата - муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән (хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хаталар) һәм документларга (муниципаль хезмәтләр нәтиҗәсе) кертелгән белешмәләргә туры килмәү сәбәпле, документларга алар буенча кертелгән белешмәләрдәге хаталар.

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза астында шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзүне яки реконструкцияләүне тәмамлау турындагы белдерү дип аңлашыла (1нче кушымта).

**2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты**

| **Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исемлеге** | **Стандартка таләпләр эчтәлеге** | **Хезмәтне яки таләпне билгеләүче норматив акт** |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтләр исемлеге | Төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге законы таләпләренә тәңгәл килүе (тәңгәл килмәве) турында белдерү җибәрү (алга таба – тәңгәл килүе (тәңгәл килмәве) турында белдерү) | РФ ШтКның 55 нче маддәсенең 19нчы өлешенең 5нче пункты |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкаручы-оештыручы органы исеме | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты | |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе язмасы | Тәңгәл килүе (тәңгәл килмәве) турында белдерү (2, 3нче кушымталар)<br>Белдерүне карамыйча кире кайтаару | РФ ШтКның 55 нче маддәсенең 19нчы өлешенең 5нче пункты |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итүнең зарурлыгын исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату вакыты, әгәр Россия Федерациясе законы тарафыннан аны туктату мөмкинлеге каралган | Тәңгәл килүе (тәңгәл килмәве) турында белдерү җибәрү – җиде көн[1] белдерү биргән көнне кертеп Төзелеш тәмамлану турындагы белдерүне карамыйча гына кайтару –өч көн | РФ ШтКның 55 нче маддәсенең 19нчы өлеше<br><br>РФ ШтКның 55 нче маддәсенең 17нче өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| булса | | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәк булган документларның тулы исемлеге, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәт, аларны гариза бирүче тәкъдим итәргә тиеш, гариза бирүче тарафыннан аларны алу мөмкинлекләре,шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе | Төзелеш тәмамлану турындагы белдерү (1нче кушымта ).<br>Белдерүгә беркетелә:<br>1) төзүченең вәкаләтләрен раслаучы документ, әгәр планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү төзүче вәкиле тарафыннан җибәрелгән булса;<br>2) әгәр төзүче чит илнең юридик заты булып торса, чит дәүләт законы нигезендә юридик затны дәүләт теркәве турындагы документларның рус телендәге расланган тәрҗемәсе;<br>3) шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының техник планы;<br>4) әгәр шәхси торак төзелеше яки бакча өе объекты төзелгән яки реконструкцияләнгән җир участогы гомуми өлешле милек хокукында ике яки берничә гражданинныкы булса яки арендатор ягыннан күп сандагы затлар белән аренда хокукында булса, төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектына гомуми өлешле милек хокукында аларның өлешләрен билгеләү турында җир хуҗалары арасында төзелгән килешү<br>Белдерү төзелешкә рөхсәт бирүгә вәкаләте булган җирле үзидарә органына кәгазьдә шәхсән мөрәҗәгать итеп, шул исәптән күп функцияле үзәк аша бирелергә мөмкин яисә тапшыру турындагы белдерү белән почта аша яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша җибәрелә. | РФ ШтКның 55 нче маддәсенең 16нчы өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Гариза бирүче тәкъдим итәргә хаклы булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәк булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе; дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма, әлеге документлар алар карамагында. | Әлеге категориягә карый торган документларны тапшыру таләп ителми | |
| 2.7. Дәүләт власте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур подразделениеләре исемлеге,норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү хезмәт күрсәтү өчен кирәк һәм ул муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан тормышка ашырыла | Килешү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | 1) белдерүдә төзелеш тәмамлану турында РФ ШтКның 55 нче маддәсенең 16нчы өлешенең беренче абзацында каралган белешмә юк;<br>2) ) төзелеш тәмамлану турындагы белдерүгә беркетелгән документлар юк;<br>3) ШтКның 55 нче маддәсенең 16нчы өлешенең 1-3 нче пунктлары белән каралган документлар юк;<br>4) әгәр төзелеш тәмамлану турындагы белдерү планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү кергәннән соң ун ел узгач керсә, шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү яки реконструкцияләү аның нигезендә гамәлгә ашырылган яисә шәхси торак төзелеше яки бакча өенең шундый объектын планлаштырылган төзү турындагы белдерү алдан җибәрелмәгән (шул исәптән ШтКның 51.1 нче маддәсенең 6нчы өлеше нигезендә төзүчегә кире кайтарылган) | |
| 2.9. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүдән баш тарту яки туктату өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен сәбәпләр каралмаган.<br><br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләр каралмаган | |
| 2.10.Муниципаль хезмәтләр күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләүләр алу тәртибе, күләме һәм сәбәбе | Муниципаль хезмәт бушлай нигездә күрсәтелә<br><br>. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Хезмәтләр күрсәткән өчен түләүләр алу тәртибе, күләме һәм сәбәбе, алар муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри, шундый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны үз эченә ала | Тиешле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12.Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорауны биргән һәм шундый хезмәт нәтиҗәсен алган вакытта чиратта торуның максималь срогы | Чират булганда муниципаль хезмәт алуга гариза бирү – 15 минуттан артмый.<br><br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13.Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы соравын теркәү срогы, шул исәптән электрон формада | Гариза кергәннән соң бер көн дәвамында<br><br>Ял көнне (бәйрәм көнне) электрон формада кергән сорау ял көненнән (бәйрәм көне) соң килүче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм кабул итү урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законы | Муниципаль хезмәтләрне күрсәтү янгынга каршы һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен тиешле җиһазлар, мәгълүмат стендлары булган зданиеләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү | Кагыйдәләр |

| | | |
|---|---|---|
| нигезендә инвалидларның күрсәтелгән объектларга керү мөмкинлекләрен тәэмин итүгә, шундый хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны визуаль, текст формасында һәм мультимедияле урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | урынына каршылыксыз кереп-чыгуы тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә бер урыннан бер урынга күчеп йөрүе).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текст формасында һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтләрне алу мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәтләрне күрсәткәндә гариза бирүченең вазифаи затлар белән үзара элемтәсе саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәтләрне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең читтәге эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны | Муниципаль хезмәтләрне алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>биналарның җәмәгать транспорты йөри торган зоналарда урнашуы;<br>кирәкле белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыручы биналарның җитәрлек санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, башкарма комитетныж мәгълүмат ресурсларында, “Интернет” челтәрендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәт алырга комачаулаучы киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br><br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты | |

| | | |
|---|---|---|
| алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләрдән файдаланып | түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларны биргәндә чиратлар булмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәтләр күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булмау;<br>муниципаль хезмәтләр күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр булмау.<br>Муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында сорау биргәндә һәм муниципаль хезмәтләр нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазифаи затның һәм гариза бирүченең үзара элемтәсе бер генә тапкыр булу күздә тотыла. Үзара элемтәнең дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәтләрне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә ( алга таба –КФҮ), КФҮнең читтәге эш урыннарында күрсәткәндә консультация, документларны кабул итү һәм тапшыруны КФҮ белгече гамәлгә ашыра.<br>Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны chistopol.tatarstan.ru сайтында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында, КФҮдә алырга мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.16.Муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтләр алу тәртибе турындагы консультацияне Интернет-кабул итү аша электрон формада яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында алырга мөмкин.<br><br>Әгәр закон тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны электрон формада бирү каралган булса, гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең ( функцияләрнең) Бердәм порталы (http:// www.gosuslugi.ru/) аша бирелә | |

[1] Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы административ процедураларны гамәлгә ашыру өчен кирәк булган минималь срокны кушудан чыгып билгеләнә. Административ процедураларның дәвамлылыгы эш көннәреннән исәпләнә.

**3. Административ процедураларның составы, эзеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрдә, күпфункцияле үзәкләрнең читтәге эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре**

3.1. Муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

1) гариза бирүче белән консультация үткәрү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) җәмәгать тикшерүләре һәм ачык тыңлаулар үткәрү һәм нәтиҗә әзерләү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен җибәрү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация күрсәтү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хаклы.

Бүлек белгече гариза бирүче белән консультация үткәрә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәтләр алу өчен башка сораулар буенча һәм әгәр кирәк булса гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пункт белән урнаштырылучы процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультация.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1.Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы кеше аша яки КФҮ аша дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрен сорап гариза бирә.

3.3.2.Оешманың гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклау;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү ( ышаныч кәгазе буенча булса);

әлеге Регламентның 2.5нче пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерү;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка төзәтүләр булмаска тиеш).

Дәгъвалар булмаган очракта Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүне кабул итә һәм махсус журналда терки;

гариза бирүчегә документларны кабул итү тамгасы белән тапшырылган документларның исемлеге күчермәсен, бирелгән керүче номерны, муниципаль хезмәт күрсәтү көнен һәм вакытын тапшыра;

планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүне Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләр булган очракта Бүлекнең гаризаларны кабул итүне алып баручы белгече гариза бирүчегә планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүне һәм тапшырылган документларны, ачыкланган сәбәпләрне күрсәтеп, кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнүче процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүне һәм документларны 15 минут эчендә кабул итү;

гариза кергәннән соң аны бер көн дәвамында теркәү;

планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүне һәм документларны карамыйча кергәннән соң бер көн дәвамында кире кайтару.

Процедура нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә карауга җибәрелгән планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүне кабул итү һәм теркәү яки гариза бирүчегә кире кайтарылган планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү һәм документлар.

3.3.3. Башкарма комитет җитәкчесе планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүне карый, башкаручыны билгели һәм гаризаны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнүче процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4 Капиталь төзелеш объектын тикшерү һәм карау үткәрү

3.4.1. Бүлек белгече:

төзелеш тәмамлану турындагы белдерүдә күрсәтелгән төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектлары параметрларының планлаштырылган төзелеш турындагы белдерү керү көненә гамәлдә булган капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкцияләүнең чик параметрларының билгеләнгән җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренең территорияне планлаштыру документациясенә һәм капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата булган мәҗбүри таләпләргә тәңгәл килүен тикшерә;

шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын карау юлы белән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының тышкы күренешенең планлаштырылган

төзелеш турындагы белдерүгә кушымта булып торучы шундый объектның яки өйнең тышкы күренеше тасвирламасына тәңгәл килүен тикшерә;

рөхсәт ителгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектыннан файдалану төренenең планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә күрсәтелгән рөхсәт ителгән файдалану төренә тәңгәл килүен тикшерә.

Әлеге пункт нигезендә урнаштырыла торган процедуралар гариза кергән вакыттан алып өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын карау.

3.5 Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Бүлек белгече тикшерү һәм карау нәтиҗәләре нигезендә тәңгәл килү ( тәңгәл килмәү) турында белдерү проекты әзерли;

документ проектын башкарма комитет җитәкчесенә ( аның вәкаләтле вәкиленә) имза куюга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар нәтиҗә кергән көннән соң ике көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкарма комитет җитәкчесенә ( аның вәкаләтле вәкиленә) имза куюга җибәрелгән документ проекты.

3.5.2. Башкарма комитет җитәкчесе ( аның вәкаләтле вәкиле) әзерләнгән документ проектына имза куя һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар карар проекты кергән көннән соң бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кул куелган һәм Бүлеккә җибәрелгән документ.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен тапшыру

3.6.1. Бүлек белгече:

тәңгәл килү (тәңгәл килмәү) турындагы белдерүне терки;

төзүчегә аның тарафыннан төзелешне тәмамлау турындагы белдерүдә билгеләнгән ысул белән тәңгәл килү (тәңгәл килмәү) турындагы белдерүне җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар башкарма комитет җитәкчесе документларга имза куйган көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә җибәрелгән муниципаль хезмәт нәтиҗәсе.

3.7.Муниципаль хезмәтне МФҮ аша күрсәтү.

3.7.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт алу өчен МФҮкә, МФҮнең читтәге эш урынына мөрәҗәгать итәргә хаклы.

3.7.2. МФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү МФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7.3. Муниципаль хезмәт алуга МФҮтән документлар кергәндә процедуралар әлеге регламентның 3.3- 3.5 пунктлары нигезендә тормышка ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе МФҮгә җибәрелә.

3.8.Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хаталар табылган очракта гариза бирүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

техник хатаны төзәтү турында гариза (1 нче кушымта);

муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак, гариза бирүчегә тапшырылган, техник хата күрсәтелгән документ;

техник хата булуын раслаучы юридик көче булган документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны гариза бирүче (аның вәкаләтле вәкиле) шәхсән үзе яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып) яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк аша тапшыра.

3.8.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, тәкъдим ителгән документлар белән гаризаны терки һәм Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән вакыттан алып бер көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә карауга җибәрелгән гаризаны кабул итү һәм теркәү .

3.8.3. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максатында әлеге Регламентның 3.5нче пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм гариза бирүчегә ( аның вәкиленә) шәхсән кул куеп төзәтелгән документны тапшыра, гариза бирүчедән ( аның вәкиленнән) техник хата киткән документның төп нөсхәсен алып, яки гариза бирүче адресына почта аша ( электрон почта чаралары аша) техник хата киткән документның төп нөсхәсен Бүлеккә тапшырган очракта, документ алу мөмкинлеге булу турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура техник хатаны тапканнан яки теләсә кайсы кызыксындырылган заттан җибәрелгән хата турында гариза алганнан соң өч көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм контрольдә тоту алымы

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедурасын үтәүгә тикшерү үткәрүне, җирле үзидарә органының вазифаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне ала.

Административ процедураларны үтәүне күзәтү өчен контроль алымнары булып торалар:

1) муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Проектларны визалау тикшерү нәтиҗәсе булып тора;

2) эш производстволарын алып баруга билгеләнгән тәртиптә тикшерүләр уздыру;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедурасын үтәүгә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының яртыеллык яки берьеллык эш планнары нәтиҗәсендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки гариза бирүченең төгәл бер мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндәге гамәлләрне кылуга контрольлек итү максатында башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча билгеләнгән административ процедуралар эшенең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольне башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары (муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшләрне оештыру өчен җаваплы), шулай ук инфраструктур үсеш бүлеге белгечләре гамәлгә ашыра.

4.3. Агымдагы контрольне тормышка ашыручы вазифаи затларның исемлеге җирле үзидарә органының структур подразделениеләре турындагы нигезләмәләре һәм вазифаи регламентлар белән билгеләнә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланганда гаепле затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җавапка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карамаган өчен җавап тота.

Җирле үзидарә органының структур подразделениесе җитәкчесе ( аның урынбасары) әлеге Регламентның 3нче бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә башкармаулары өчен җавап тота.

Вазифаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кулланылучы (гамәлгә ашырылучы) карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары ) өчен Закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә җаваплылар.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан муниципаль хезмәт күрсәтүгә контроль муниципаль хезмәт күрсәткәндә башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль

һәм дөрес мәгълүмат алу юлы һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне судка кадәр карау мөмкинлеге белән тормышка ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазифаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең гамәлләренә (чара күрмәүләренә) судка кадәрге (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерергә хаклылар.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең соравын теркәү срогын бозу, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 15.1 нче маддәсендә күрсәтелгән сорау;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлары белән каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә башка гамәлләрне, күрсәтмәләрне таләп итә алмый;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең, норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлары, әлеге Административ регламент белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тарту нигезләре федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив- хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар тарафыннан каралмаган булса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм

гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар белән каралмаганда, түләү таләп итү;

7) башкарма комитет, башкарма комитетның вазифаи затының, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 27.07.2010елгы 210 нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешманың яки аның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда киткән хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуы. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса;

8) муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срокларын һәм тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату, әгәр туктату сәбәпләре федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар тарафыннан каралмаган булса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса;

10) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны (аларның булмаулары һәм (яки) дөрес булмаулары) таләп итү яисә 27.07.2010 елгы 210

нчы Федераль законның 7нче маддәсенең 1 өлешенең 4 нче бүлегендә каралган очраклардан кала, дәүләт яки муниципаль хезмәте күрсәтү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

5.2. Гариза бирүчеләр шикаятьне нигезләү һәм карау өчен мәгълүмат һәм документлар алырга хокуклы.

5.3. Шикаять муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып торучы дәүләт властеның ( җирле үзидарә органы) ачык-хокукый берәмлеге булган тиешле органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне оештыручы), шулай ук 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмаларга язмача формада кәгазьдә һәм электрон формада бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять югарыгы органга ( әгәр ул булса) бирелә яисә ул булмаганда турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять күпфункцияле үзәкне оештыручыга яисә Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары буенча вәкаләте булган вазифаи затка бирелә. 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәк, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша,

“Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмалар, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән хезмәт күрсәтүче орган, хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының исеме яки муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме ( соңгысы әгәр булса), яшәү урыны турында белешмә , шулай ук элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы (әгәр булса) һәм почта адресы, аның буенча гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү турында белешмә;

4) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең гариза бирүченең хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмауларына) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр. Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслаучы (алар булганда) документлар яисә аларның күчермәләре.

5.5. Шикаятьне карау өчен әһәмияткә ия булган документлар булмаса яки алар шикаятькә беркетелмәгән булса, карар дәлилләрне (аларны раслау өчен документлар тәкъдим ителмәгән) исәпкә алмыйча гына кабул ителә.

5.6. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкне оештыручыга, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмаларга яисә

югарыгы органга (әгәр ул булса) кергән шикаять аны теркәгәннән соң унбиш эш көне дәвамында каралырга тиеш. Әгәр муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешма гариза бирүчедән документларны кабул итүгә яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартса яки шундый төзәтүләрнең срогын бозуга шикаять белдерелсә - аны теркәгәннән соң биш эш көне дәвамында.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәт күрсәтүче орган түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү формасында, гариза бирүчегә акчаны кире кайтару, әгәр акча алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, Чистай муниципаль районының норматив-хокукый актлары белән каралмаган булса;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта:

5.8. Карарны кабул иткән көннән соң килә торган көннән соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача формада һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән җавап җибәрелә.

Шикаятьне канәгатьләндерергә кирәк дип тапкан очракта, гариза бирүчегә җавапта муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган бозуларны тиз арада бетерү максатында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк яисә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешма тарафыннан тормышка ашырылучы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китергән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм муниципаль хезмәт алу максатында гариза бирүчегә алга таба нәрсә эшләргә кирәклеге турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерерлек дип табылмаган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында аргументлаштырылган аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки шикаятьне карау буенча вәкаләтләре булган вазифаи затның, хезмәткәрнең җинаятьләре ачыкланса, тиз арада булган материаллар прокуратура органнарына җибәрелә.

1нче кушымта
ФОРМА

**Шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзүне яки реконструкцияләүне тәмамлау турындагы белдерү**

«___» ___________ 20___ел

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(төзелешкә рөхсәт бирүгә вәкаләт булган башкарма властьның федераль органы, Россия Федерациясе субъектының башкарма власте органы, җирле үзидарә органы исеме)

**1. Төзүче турында белешмә**

| | | |
|---|---|---|
| 1.1 | Физик зат турында белешмә, әгәр төзүче физик зат булып торса: | |
| 1.1.1 | Фамилиясе, исеме атасының исеме (әгәр булса) | |
| 1.1.2 | Яшәү урыны | |
| 1.1.3 | Шәхесне раслаучы документ реквизитлары | |
| 1.2 | Юридик зат турында белешмә, әгәр төзүче юридик зат булып торса | |
| 1.2.1 | Исеме | |
| 1.2.2 | Урнашкан урыны | |
| 1.2.3 | Юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрында дәүләт теркәве турындагы язуның дәүләт теркәү номеры, гариза бирүче булып чит илнең юридик заты торган очрактан кала | |
| 1.2.4 | Салым түләүченең идентификацион номеры, гариза бирүче булып чит илнең юридик заты торган очрактан кала | |

**2. Җир участогы турында белешмә**

| | | |
|---|---|---|
| 2.1 | Җир участогының кадастр номеры (әгәр булса ) | |
| 2.2 | Җир участогының адресы яки урнашу урынын тасвирлау | |
| 2.3 | Төзүченең җир участогына хокукы турындагы белешмә (хокукны билгеләүче документлар) | |
| 2.4 | Башка затларның җир участогына хокукы булу турындагы белешмә (әгәр булса) | |
| 2.5 | Җир участогыннан файдалануның рөхсәт ителгән төре турында белешмә | |

**3. Капиталь төзелеш объекты турында белешмә**

| | | |
|---|---|---|
| 3.1 | Капиталь төзелеш объектыннан файдалануның рөхсәт ителгән төре турында белешмә (шәхси торак төзелеше яки бакча өе объекты ) | |
| 3.2 | Белдерүне бирү максаты (төзелеш яки реконструкция) | |
| 3.3 | Параметрлары турында белешмә: | |
| 3.3.1 | Җир өстендәге катлар саны | |
| 3.3.2 | Биеклек | |
| 3.3.3 | Җир участогы чикләреннән читкә чыгу турында белешмә | |
| 3.3.4 | Төзелеш мәйданы | |

**4. Җир участогында  төзелгән яки реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының схемалы рәсеме**

Элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адрес:

______________________________________________________________________

Төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә тәңгәл килүе турындагы белдерүне яисә төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә тәңгәл килмәве турындагы белдерүне түбәндәге ысул белән җибәрүегезне сорыйм: ______________________________________

______________________________________________________________________

(почта адресына һәм (яки) электрон почта адресна җибәрү юлы белән яки төзелешкә рөхсәт бирүгә вәкаләте булган башкарма властьның федераль органында, Россия Федерациясе субъектының башкарма власте органында, җирле үзидарә органында, шул исәптән күп функцияле үзәк аша кулдан тапшырып)

**Әлеге белдерү белән шуларны раслыйм,** ______________________________

(шәхси торак төзелеше яки бакча өе объекты)

**күчемсез милекнең мөстәкыйль объектларына бүлү өчен, шулай ук хокукны дәүләт теркәвен тормышка ашыру өчен дәүләт пошлинасы түләү билгеләнмәгән.**

______________________________________________________________________.

(түләү документы реквизитлары)

**Әлеге белдерү белән мин** ______________________________________

______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (әгәр булса)

**персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм (әгәр төзүче физик зат булып торса).**

| ______________________ | ______________ | ______________________ |
|---|---|---|
| (вазифа, әгәр төзүче юридик зат булып торса) | (имза) | (имзаны расшифровкалау) |

М.У.

(булганда)

Әлеге белдерүгә беркетелә:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 55нче маддәсенең 16 нчы өлешендә каралган документлар (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы , 2005, № 1, 16 нчы маддә; 2006, № 31, 3442 нчы маддә; № 52, 5498 нчы маддә; 2008, № 20, 2251 нче маддә; № 30, 3616 нчы маддә; 2009, № 48, 5711 нче маддә; 2010, № 31, 4195 нче маддә; 2011, № 13, 1688 нче маддә; № 27, 3880 нче маддә; № 30, 4591 нче маддә; № 49, 7015 нче маддә; 2012, № 26, 3446 нчы маддә; 2014, № 43, 5799 нчы маддә; 2015, № 29, 4342, 4378 нче маддәләр; 2016, № 1, 79 нчы маддә; 2016, № 26, 3867 нче маддә; 2016, № 27, 4294, 4303, 4305, 4306 нче маддәләр; 2016, № 52, 7494 нче маддә; 2018, № 32, 5133, 5134, 5135нче маддәләр)

2нче кушымта

ФОРМА

___

төзелешкә рөхсәт бирүгә вәкаләте булган башкарма властьның федераль органы, Россия Федерациясе субъектының башкарма власте органы, җирле үзидарә органы исеме

Кемгә:

___

___

___

Почта адресы: ___

___

___

Электрон почта адресы (булганда): ___

___

**Төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә тәңгәл килүе турындагы белдерү**

«___» ___________ 20___ ел № _____________

Шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзүне яки реконструкцияләүне тәмамлау турындагы белдерүне **карау нәтиҗәләре буенча**
(алга таба – белдерү),

җибәрелгән
(белдерүне җибәрү көне) ___________________________________________

теркәлгән
(белдерүне теркәү көне һәм номеры ) ___________________________________________

**тәңгәл килүе турында белдерә** ___________________________________________
(төзелгән яки реконструкцияләнгән)

___________________________________________,
(шәхси торак төзелеше яки бакча өе объекты )

белдерүдә күрсәтелгән һәм җир участогында урнашкан

___________________________________________

___________________________________________
(җир участогының кадастр номеры (булганда), җир участогының адресы яки урнашу урыны тасвирламасы)

шәһәр эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә

| | | |
|---|---|---|
| ___________________________ | _____________ | _____________ |
| (төзелешкә рөхсәт бирүгә вәкаләте булган башкарма властьның федераль органының, Россия Федерациясе субъектының башкарма власте органының, җирле үзидарә органының вәкаләтле заты вазифасы) | (имза) | (имзаны расшифровкалау) |

М.У.

3нче кушымта

ФОРМА

______________________________________________________________________

төзелешкә рөхсәт бирүгә вәкаләте булган башкарма властьның федераль органы, Россия Федерациясе субъектының башкарма власте органы, җирле үзидарә органы исеме

Кемгә:

________________________________________

________________________________________

________________________________________

Почта адресы: __________________________

________________________________________

________________________________________

Электрон почта адресы
(булганда): __________________________

________________________________________

**Төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә тәңгәл килмәве турындагы белдерү**

«___» ____________ 20___ ел № ______________

Шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзүне яки реконструкцияләүне тәмамлау турындагы белдерүне **карау нәтиҗәләре буенча**
(алга таба – белдерү),
җибәрелгән
(белдерүне җибәрү көне) ______________________________________________
теркәлгән
(белдерүне теркәү көне һәм номеры ) ______________________________________________

**тәңгәл килмәве турында белдерә** _________________________________________________________________

(төзелгән яки реконструкцияләнгән)

____________________________________________________________________________________________,

(шәхси торак төзелеше яки бакча өе объекты )

белдерүдә күрсәтелгән һәм җир участогында урнашкан

____________________________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________________________

(җир участогының кадастр номеры (булганда), җир участогының адресы яки урнашу урыны тасвирламасы)

шәһәр эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә түбәндәге сәбәпләр буенча:

1. __________________________________________________________________________________________

(төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55нче маддәсенең 19нчы өлешендәге 1нче пунктында (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы , 2005, № 1, 16 нчы маддә; 2018, №32, 5135нче маддә) күрсәтелгән параметрларының рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре белән билгеләнгән чик параметрларына, территорияне

планлаштыру буенча документациягә яки Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, башка федераль законнар тарафыннан билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының чик параметрларына тәңгәл килмәве турында белешмә)

2. ______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектының тышкы күренешенең планлаштырылган шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү һәм реконструкцияләү турындагы белдерүгә кушымта булып торган шундый объектның яки өйнең тышкы күренеше тасвирламасына (алга таба – планлаштырылган төзелеш турында белдерү) яки планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә күрсәтелгән типовой архитектура карарына тәңгәл килмәве турындагы белешмә яки төзүчегә планлаштырылган шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын төзү һәм реконструкцияләү турындагы белдерүдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга тәңгәл килмәве һәм (яки) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51.1нче маддәсенең 10нчы өлешендәге 4нче пунктында (Россия Федерациясенең Законнар җыентыгы, 2005, № 1, 16 нчы маддә; 2018, №32, 5133, 5135нче маддәләр, әгәр шәхси торак төзелеше яки бакча өе объекты федераль һәм төбәк билгеләнешендәге тарихи җирлек чикләрендә төзелсә яки реконструкцияләнсә ) күрсәтелгән сәбәп буенча җир участогында шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын урнаштыру мөмкин булмавы турындагы белешмә җибәрелгән)

3. ______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(төзелгән яки реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектыннан файдалануның рөхсәт ителгән төренең планлаштырылган төзелеш турындагы белдерүдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектыннан файдалануның рөхсәт ителгән төренә тәңгәл килмәве турындагы белешмә)

4. ______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(белдерү керү көненә Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләр нигезендә шәхси торак төзелеше яки бакча өе объектын урнаштыру мөмкин булмавы турындагы белешмә, күрсәтелгән чикләүләр төзү, реконструкцияләү планлаштырылган капиталь төзелеш объектына карата территориядән файдалануның аерым шартлары булган зоны билгеләү яки үзгәртү турындагы карарда каралган һәм шундый капиталь төзелеш объекты файдалануга кертелмәгән очраклардан кала)

| | | |
|---|---|---|
| ______________________________ | ______________ | ____________________ |
| (төзелешкә рөхсәт бирүгә вәкаләте булган башкарма властьның федераль органының, Россия Федерациясе субъектының башкарма власте органының, җирле үзидарә органының вәкаләтле заты вазифасы) | (имза) | (имзаны расшифровкалау) |

М.У.

4нче кушымта

Татарстан Республикасы  Чистай муниипаль  районы башкарма комитеты җитәкчесенә

___________________________________

_____________________

кемнән:__________________________

_____________________

**Техник хатаны  төзәтү турында**
**гариза**

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән  хата турында хәбәр итәм

________________________________________________________________________________

(хезмәт исеме)

Язылган:_______________________________________________________________

___________________________________________________________________________

Дөрес  мәгълүматлар:___________________________________________________

___________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт  нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.Түбәндәге документларны беркетәм:

1.
2.
3.

Техник  хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул иткән очракта менә шундый карар җибәрүегезне сорыйм:

электрон документны җибәрү чарасы белән  E-mail адресына:_______;

расланган күчермә төрендә булганда  кәгазьдә почта аша: _________________________________________________________________.

*Муниципаль хезмәт күрсәтү максатында персональ мәгълүматларны (җыю, системага салу, туплау, саклау, юк итү (яңарту, үзгәртү),файдалану, тарату ( шул исәптән тапшыру) блокировкалау, персонал мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль күрсәтү күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәк булган башка гамәлләр), шул исәптән  алар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карар кабул итүне кертеп, автоматлаштырылган режимда персональ мәгълүматларны эшкәртүгә үземнең, шулай ук  минем вәкилемнең килешүен раслыйм.*

*Раслыйм: минем шәхесемә һәм вәкилемнең шәхесенә кагылышлы  гаризага*

*кертелгән хәбәрләр, шулай ук астарак минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага беркетелгән документлар (аларның күчермәләре) Россия Федерациясе законы тарафыннан билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны бирү вакытына әлеге документлар үз көчендә иде һәм анда дөрес мәгълүматлар тупланган.*
*Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон буенча сораштыруда катнашырга риза.* ___________________

______________ __________________ ( _________________)
(дата) (имза) (Ф.И.О.)

Кушымта
(белешмә)

**Муниципаль хезмәт күрсәтүгә һәм аның үтәлешенә контрольлек итүгә җаваплы булган вазифаи затларның реквизитлары**

**Чистай муниципаль районы башкарма комитеты**

| Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | **(84342) 5-10-84** | Chistay@tatar.ru |
| Бүлек начальнигы | **(84342)5-15-65** | Chis.Arhitek@tatar.ru |
| Бүлек белгече | **(84342)5-14-15** | Marat.Bibishev@tatar.ru |

**Чистай муниципаль районы Советы**

| Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башлык | **(84342)5-43-70** | Chistay@tatar.ru |